Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге Советы Карары

20 январь 2020 ел № 119

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге «Җир салымы турында " 102 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 31нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Уставы нигезендә, Өҗем авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге 102 номерлы «Җир салымы турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

2.2. 0,12 процент Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары яки индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган җир кишәрлегеннән һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) ;

**1.2. 4.2 пунктта сүзтезмәне төшереп калдырырга** :
« яки шәхси эшмәкәрләр булган физик затлар»

**1.3. 5 пунктны төшереп калдырырга .**

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб – адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл башлыгы А.Т.Вәлиев